МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.03.2016 Казан ш. №72

**Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайлау комиссиясе турында нигезләмәне раслау хакында**

«Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законнарга, Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайлау комиссиясе турында» 2010 елның 1 июлендәге 821нче Указына, «Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайлау комиссиясе турында» 2010 елның 25 августындагы УП-569 номерлы Указына ярашлы рәвештә **боерам:**

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайлау комиссиясе турында әлеге боерыкка теркәлгән Нигезләмәне расларга.

2. Кадрлар бүлегенә (В.Р.Садыйкова) әлеге боерыкны, билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве үткәрү өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына юлларга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

**Министр** **А.А.Здунов**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгы
боерыгы белән расланган
18.03.2016 № 72

**Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайлау комиссиясе турында**
**Нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайлау комиссиясе турында Нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) «Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законнарга, Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайлау комиссиясе турында» 2010 елның 1 июлендәге 821нче Указына, «Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайлау комиссияләре турында» 2010 елның 25 августындагы УП-569 номерлы Указына нигезләнеп эшләнде. Нигезләмә белән Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайлау комиссиясе (алга таба – Комиссия) эшчәнлеге һәм аны формалаштыру тәртибе билгеләнә.

1.2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3. Комиссиянең төп бурычы - Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына (алга таба – Министрлык) түбәндәгеләр буенча ярдәм итү:

а) Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре, Министрлык) тарафыннан чикләүләрнең һәм тыюларның саклануын, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмый калу һәм җайлауга карата таләпләрне үтәүне, һәм шулай ук алар тарафыннан «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елдагы 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законнарда, башка федераль законнарда билгеләнгән

бурычларны үтәүне тәэмин итүгә (алга таба – хезмәт урынындагы тәртипкә карата таләпләр һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайлауга карата таләпләр);

б) Министрлыкта коррупцияне кисәтү буенча чаралар күрүгә.

1.4. Комиссия Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын (алга таба – дәүләт хезмәте вазыйфалары) биләүче дәүләт хезмәткәрләренә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан хезмәткә билгеләнә һәм азат ителә торган дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәрләреннән тыш) карата хезмәт урынындагы тәртипкә куелган таләпләрнең үтәлешенә һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайлауга куелган таләпләрнең үтәлешенә бәйле сорауларны карый.

1.5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан хезмәткә билгеләнә һәм азат ителә торган дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәрләренә карата хезмәт урынындагы тәртипкә куелган таләпләрнең үтәлешенә һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайлауга куелган таләпләрнең үтәлешенә бәйле сораулар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында төзелгән дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайлау комиссиясе тарафыннан карала.

1.6. Комиссия җинаятьләр һәм административ хокук бозулар турындагы хәбәрләрне, һәм шулай ук аноним мөрәҗәгатьләрне карамый, хезмәт дисциплинасын бозу фактлары буенча тикшерүләр үткәрми.

## II. Комиссия составы

2.1. Комиссия составы Министрлык боерыгы белән раслана. Комиссия составына Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче Комиссия әгъзалары арасыннан министр тарафыннан билгеләнә торган Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары, Комиссия секретаре һәм Комиссия әгъзалары керә. Комиссия әгъзаларының барысы да карар кабул иткәндә тигез хокукка ия. Комиссия рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

2.2. Комиссия составына түбәндәгеләр керә:

а) министр урынбасары (Комиссия рәисе), Министрлык кадрлар бүлегенең коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты (Комиссия секретаре), кадрлар бүлеге башлыгы, юридик бүлек башлыгы, министр тарафыннан билгеләнә торган Министрлыкның башка бүлекләре хезмәткәрләре;

б) Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе һәм (яисә) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре подразделениесе вәкилләре;

в) эшчәнлекләре дәүләт хезмәте белән бәйле фәнни оешмалар, һөнәри белем бирү оешмалары, югары белем бирү мәгариф оешмалары һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары вәкиле (вәкилләре).

2.3. Министр Министрлык каршындагы Иҗтимагый оешма, Министрлыкның беренчел профсоюз оешмасы һәм Министрлык каршындагы Ветераннывр советы

вәкилләрен Комиссия составына кертү турында карар кабул итә ала.

2.4. Нигезләмәнең 2.2 пункты «б» һәм «в» пунктчаларында һәм 2.3 пунктында күрсәтелгән затлар Комиссия составына билгеләнгән тәртиптә министр гарызнамәсе буенча тиешле органнар һәм оешмалар белән килештерелеп кертелә.

2.5. Комиссия әгъзаларының Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләмәгәннәренең саны Комиссия әгъзаларының гомуми санының дүрттән береннән дә ким булмаска тиеш.

2.6. Комиссия составы Комиссия тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясарлык мәнфәгатьләр конфликтларының булу мөмкинлеген юкка чыгарырлык итеп формалаштырыла.

2.7. Комиссия утырышларында киңәш хокукына ия түбәндәге затлар катнаша ала:

а) Комиссия тарафыннан хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтларын җайлау турында таләпләрнең үтәлеше турындагы сорау каралуга мөнәсәбәте булган дәүләт хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесе һәм Комиссия рәисе тарафыннан билгеләнә торган һәм Министрлыкта Комиссиядә карала торган сорауга кагылышы булган дәүләт хезмәткәре биләгән дәүләт хезмәте вазыйфасына охшаш вазыйфа биләгән ике дәүләт хезмәткәре;

б) Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфалары биләгән башка дәүләт хезмәткәрләре; Комиссия тарафыннан карала торган сораулар һәм дәүләт хезмәте сораулары буенча аңлатма бирә алырлык белгечләр; башка дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары; кызыксынган як оешмалары вәкилләре; Комиссия тарафыннан хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтларын җайлау турында таләпләрнең үтәлеше турындагы сорау каралуга мөнәсәбәте булган дәүләт хезмәткәренең вәкиле – Комиссия рәисе карары буенча. Карар Комиссия тарафыннан каралган сорауга кагылышы булган дәүләт хезмәткәренең яисә Комиссиянең теләсә кайсы әгъзасының үтенеч язуы нигезендә һәр конкрет очрак өчен аерым, Комиссия утырышына кадәр өч көннән дә соңга калмый кабул ителә.

2.8. Комиссия утырышы Комиссия әгъзалары гомуми санының өчтән икесе катнашканда тулы хокуклы дип санала. Утырыш Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче Комиссия әгъзалары катнашындагы гына үткәрелергә тиеш түгел.

2.9. Комиссия әгъзасының Комиссия утырышының көн тәртибенә кертелгән сорау каралганда мәнфәгатьләр конфликтына китерәчәк турыдан-туры яисә турыдан-туры булмаган шәхси кызыксынуы туганда, ул бу турыда утырыш алдыннан әйтергә тиеш. Бу очракта әлеге Комиссия әгъзасы сорауны тикшерүдә катнашмый.

## III. Комиссиянең эшләү тәртибе

3.1. Комиссия утырышын уздыру өчен түбәндәгеләр нигез булып тора ала:

а) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына ярашлы рәвештә дәүләт хезмәткәре биргән мәгълүматның дөреслеген һәм

тулылыгын һәм хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрнең дәүләт хезмәткәре тарафыннан үтәлешен тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәгеләрне дәлилли торган тикшерү материалларының министр тарафыннан тәкъдим ителүе:

дәүләт хезмәткәре тарафыннан Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге УП-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы мәгълүмат тапшырылу турындагы Нигезләмәдә каралган дөрес булмаган һәм тулы булмаган мәгълүмат тапшырылуы турында;

дәүләт хезмәткәре тарафыннан хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтларын җайлау турында таләпләрнең сакланмавы турында;

б) Министрлыкның норматив хокукый акты белән билгеләнгән тәртиптә кадрлар бүлегенә кергән түбәндәгеләр:

Министрлык боерыгы белән расланган, Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгәндә үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һә мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү мәҗбүри булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә кергән дәүләт хезмәте биләгән гражданинның коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада вазыйфа биләүгә яисә коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада граждан-хокукый шартнамә шартларында эш башкаруга ризалык бирү турында, әгәр әлеге оешма белән дәүләт идарә итүенең аерым функцияләре аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса (дәүләт хезмәтеннән азат ителүгә ике ел үткәнче);

дәүләт хезмәткәренең объектив сәбәпләр буенча хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы бурычлары турында мәгълүматны тапшырып булмавы турындагы гаризасы;

дәүләт хезмәткәренең счетлар (кертемнәр) урнашкан, чит ил банкларында акчаларның һәм кыйммәтле әйберләрнең сакланышы тәэмин ителгән һәм (яисә) финанс инструментлар булдырылган әлеге чит ил законнарына ярашлы рәвештә чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан салынган күрсәтмәләрне тыюга, арестка һәм аның ихтыярына яисә аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының ихтыярына бәйсез рәвештә, «Аерым затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында акчалар һәм кыйммәтле әйберләрне саклау, счетлар (кертемнәр) ачу һәм булдыру, чит ил финанс инструментларын булдыру һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәп булмавы турындагы гаризасы;

дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын башкарганда мәнфәгатьләр конфликтына китерүче һәм китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка

килүе турындагы хәбәре;

в) министрның яисә Комиссиянең теләсә кайсы әгъзасының Министрлыкта коррупцияне кисәтү буенча чараларны гамәлгә ашыруга яисә дәүләт хезмәткәре тарафыннан хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайлау турындагы таләпләрнең үтәлешен тәэмин итүгә кагылышлы хәбәре;

г) министр тарафыннан дәүләт хезмәткәренең «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүенә контроль турында» Федераль законның 3 маддәсенең 1 өлешендә каралган дөрес булмаган һәм тулы булмаган мәгълүмат бирүен дәлилләүче тикшерү материалларын күрсәтелүе;

д) Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 64.1 маддәсе һәм «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 маддәсе 4 өлешенә ярашлы рәвештә коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмаларның Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче гражданин белән эш башкаруга (хезмәт күрсәтүгә) хезмәт һәм граждан-хокукый шартнамә төзү турында (әгәр әлеге оешма белән дәүләт идарә итүе кайбер функцияләре Министрлыкта вазыйфа башкарганда аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына керсә) Министрлыкка юллаган хәбәре, әгәр әлеге гражданинга элегрәк Комиссия тарафыннан бу оешма белән хезмәт һәм граждан-хокукый мөнәсәбәтләргә керү тыелган һәм Комиссия тарафыннан әлеге гражданинга коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмаларда вазыйфа биләү яисә коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмаларда граждан-хокукый шартнамә шартларында эшләр башкаруга ризалык бирү турында сорау каралмаган булса;

3.2. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пункты «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданин тарафыннан кадрлар бүлегенә тапшырыла. Мөрәҗәгатьтә түбәндәгеләр күрсәтелә: фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы, яшәү урыны адресы, дәүләт хезмәтеннән азат ителгән көннән башлап соңгы ике ел дәвамында биләгән вазыйфалары, коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешманың исеме, урнашкан урыны, эшчәнлеге характеры, дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләгәндә гражданин тарафыннан башкарылган вазыйфаи (хезмәт) бурычлар, коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмага карата дәүләт идарәсе буенча функцияләре, шартнамә төре (хезмәт яисә граждан-хокукый), аның гамәлдә булуының ниятләнелгән срогы, шартнамә буенча эшләр (хезмәт күрсәтүләр) башкаруга түләү суммасы. Мөрәҗәгать кадрлар бүлегендә карала. Аның нәтиҗәләренә карап, мөрәҗәгатьнең эчтәлеге буенча дәлилләнгән бәяләмә әзерләнә. Анда «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 маддәсе таләпләре исәпкә алына.

3.3. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пункты «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать дәүләт хезмәтеннән китәргә ниятләгән дәүләт хезмәткәре тарафыннан бирелә ала һәм, әлеге Нигезләмәгә ярашлы рәвештә, Комиссия тарафыннан каралырга тиеш.

3.4. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пункты «д» пунктчасында күрсәтелгән хәбәр коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эш өчен җаваплы

зат тарафыннан карала. Ул Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче гражданин тарафыннан «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль закон таләпләренең үтәлеше турында дәлилләнгән бәяләмә әзерли.

3.4.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пункты «б» пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән хәбәр коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эш өчен җаваплы зат тарафыннан карала. Ул хәбәрне карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән бәяләмә әзерли.

3.4.2. Әлеге Нигезләмәнең 3.1. пункты «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне, яисә әлеге Нигезләмәнең 3.1. пункты «б» пунктчасының бишенче абзацында һәм әлеге Нигезләмәнең 3.1 пункты «д» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрне карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән бәяләмәне әзерләгәндә коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эш өчен җаваплы зат мөрәҗәгать яисә хәбәр тапшырган дәүләт граждан хезмәткәре белән әңгәмә үткәрергә һәм аңардан язмача аңлатмалар алырга хокуклы. Мәгълүмат алу өчен Министрлык тарафыннан дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксындыру уяткан оешмаларга гарызнамәләр юллана ала. Мөрәҗәгать яисә хәбәр, һәм шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар, мөрәҗәгать яисә хәбәр кергәннән соң, җиде эш көне эчендә Комиссия рәисенә тапшырыла. Гарызнамәләр юлланган очракта мөрәҗәгать яисә хәбәр, һәм шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар Комиссия рәисенә, мөрәҗәгатьләр һәм хәбәрләр кергәннән соң, 45 көн эчендә тапшырыла. Билгеләнгән срок Комиссия рәисе тарафыннан озайтылырга мөмкин, ләкин 30 көннән дә күбрәккә түгел.

3.5. Комиссия утырышын үткәрү өчен нигез булырдай мәгүлүмат кергәннән соң, Комиссия рәисе түбәндәгеләрне эшли:

а) 10 көн эчендә Комиссия утырышы датасын билгели. Шул ук вакытта Комиссия утырышы датасы, әлеге мәгълүмат кергәннән соң, 20 көннән дә соңракка билгеләнә алмый, әлеге Нигезләмәнең 3.6 һәм 3.7 пунктларында каралган очраклардан тыш;

б) Комиссия тарафыннан хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтларын җайлау турында таләпләрнең үтәлеше турындагы сорау каралуга мөнәсәбәте булган дәүләт хезмәткәренең, аның вәкиленең, Комиссия әгъзаларының һәм Комиссия утырышында катнашучы башка затларның кадрлар бүлегенә кергән мәгълүмат, һәм шулай ук әлеге мәгълүматны тикшерү нәтиҗәләре белән танышуын оештыра;

в) әлеге Нигезләмәнең 2.7 пункты «б» пунктчасында күрсәтелгән затларны Комиссия утырышына чакыру турындагы үтенечләрне карый, аларны канәгатьләндерү (канәгатьләндерүдән баш тарту) турында һәм Комиссия утырышы барышында өстәмә материалларны карау (караудан баш тарту) турында карарлар кабул итә.

3.6. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пункты «б» пунктчасының өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән гаризаларны карау буенча Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат тапшыру өчен билгеләнгән срок үткәннән соң бер айдан да соңга калмый уздырыла.

3.7. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пункты «д» пунктчасында күрсәтелгән хәбәр, кагыйдә буларак, Комиссиянең чираттагы (план буенча үткрелә торган) утырышында карала.

3.8. Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтларын җайлау турында таләпләрнең үтәлеше турындагы сорау каралуга мөнәсәбәте булган дәүләт граждан хезмәткәре яисә Министрлыкта дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләүче гражданин катнашлыгында уздырыла. Комиссия утырышында шәхсән үзе катнашу ниятен дәүләт граждан хезмәтләре яисә гражданин әлеге Нигезләмәнең 3.1 пункты «б» пунктчасына ярашлы рәвештә тапшырыла торган мөрәҗәгатьтә, гаризада яисә хәбәрдә күрсәтергә тиеш.

3.8.1. Комиссия утырышлары түбәндәге очракларда дәүләт граждан хезмәткәре яисә гражданин булмаганда үткәрелә ала:

а) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пункты «б» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьтә, гаризада яисә хәбәрдә Комиссия утырышында дәүләт граждан хезмәткәре яисә гражданинның шәхсән катнашу нияте турында күрсәтмә булмаса;

б) әгәр Комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте булган дәүләт граждан хезмәткәре яисә гражданин, утырышның үткәрелү вакыты һәм урыны турында тиешле рәвештә хәбәр ителеп тә, Комиссия утырышына килмәсә.

3.9. Комиссия утырышында дәүләт граждан хезмәткәренең һәм Министрлыкта дәүләт граждан хезмәткәре вазыйфасын биләүче гражданинның һәм башка затларның аңлатмалары тыңлана (алар рөхсәте белән), әлеге утырышның көн тәртибенә куелган сорауларның асылы буенча материаллар, һәм шулай ук өстәмә материаллар карала.

3.10. Комиссия әгъзаларының һәм утырышта катнашучы затларның Комиссия эше барышында билгеле булган мәгълүматларны таратырга хаклары юк.

3.11. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пункты «а» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән сорауны карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге УП-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат, һәм шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы мәгълүмат тапшыру турындагы Нигезләмәдә каралган мәгълүматларның дәүләт хезмәткәре тарафыннан дөрес һәм тулы күләмдә тапшырылган булуын танырга;

б) әлеге пунктның беренче абзацындагы аталган Нигезләмәгә ярашлы дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган мәгълүматларның дөрес булмавын һәм (яисә) тулы булмавын билгеләргә. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын күрергә тәкъдим итә.

3.12. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пункты «а» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән сорауны карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан хезмәт урынындагы тәртибенә карата

таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайлауга карата таләпләрнең үтәлгән булуын танырга;

б) дәүләт хезмәткәре тарафыннан хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайлауга карата таләпләрнең үтәмәгән булуын танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә хезмәт урынындагы тәртибен бозуга карата һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайлауга карата таләпләрнең үтәлешен сакларга күрсәтмә бирергә яисә дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын күрергә тәкъдим итә.

3.13. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пункты «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән сорауны карау буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) гражданинга коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмаларда вазыйфа биләүгә яисә коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмаларда граждан-хокукый шартнамә шартларында эшләр башкаруга рөхсәт бирергә, әгәр әлеге оешма белән дәүләт идарә итүенең кайбер функцияләре аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына керсә;

б) гражданинга коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмаларда вазыйфа биләүгә яисә коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмаларда граждан-хокукый шартнамә шартларында эшләр башкаруга (әгәр әлеге оешма белән дәүләт идарә итүенең кайбер функцияләре аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына керсә) рөхсәт бирүдән баш тартырга һәм баш тартуны дәлилләргә.

3.14. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пункты «б» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән сорауны карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт граждан хезмәткәре тарафыннан үзенең хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат тапшырылмавы сәбәбенең объектив һәм нигезле булуын танырга;

б) дәүләт граждан хезмәткәре тарафыннан үзенең хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат тапшырылмавы сәбәбенең нигезле булмавын танырга. Бу очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә тиешле мәгълүматларны тапшыру буенча чаралар күрергә тәкъдим итә;

в) дәүләт граждан хезмәткәре тарафыннан үзенең хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат тапшырылмавы сәбәбенең объектив булмавын һәм моны күрсәтелгән мәгълүматларны тапшырудан баш тарту ысулы дип танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын күрергә тәкъдим итә.

3.15. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пункты «б» пунктчасының дүртенче абзацында күрсәтелгән сорауны карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) «Аерым затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм алаларга ия булу, кулда булган акчаларын һәм кыйммәтле әйберләрен саклау, чит ил финанс инструментларына ия

булу һәм (яисә) аларны куллануны тыю турында»гы Федераль закон таләпләрен үтәүгә комачаулый торган хәлләрне объектив һәм нигезле дип танырга;

б) «Аерым затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм алаларга ия булу, кулда булган акчаларын һәм кыйммәтле әйберләрен саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яисә) аларны куллануны тыю турында»гы Федераль закон таләпләрен үтәүгә комачаулый торган хәлләрнең объектив булмавын һәм нигезле булмавын танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын күрергә тәкъдим итә.

3.15.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пункты «б» пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән сорауны карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт граждан хезмәткәре тарафыннан вазыйфаи бурычлар башкарылганда мәнфәгатьләр конфликты тумавын танырга;

б) дәүләт граждан хезмәткәре тарафыннан вазыйфаи бурычлар башкарылганда шәхси кызыксыну мәнфәгатьләр конфликтына китерүен яисә китерә алуын танырга. Бу очракта Комиссия дәүләт граждан хезмәткәренә һәм (яисә) министрга мәнфәгатьләр конфликтын җайлау яисә аны булдырмый калу буенча чаралар күрергә тәкъдим итә:

в) дәүләт граждан хезмәткәренең мәнфәгатьләр конфликтын җайлауга карата таләпләрне үтәмәвен танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт граждан хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын күрергә тәкъдим итә.

3.16. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пункты «в» пунктчасында күрсәтелгән сорауны карау нәтиҗәләре буенча Комиссия тиешле карарны кабул итә.

3.17. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пункты «г» пунктчасында күрсәтелгән сорауны карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүенә контроль турында» Федераль законның 3 маддәсе 1 өлешенә ярашлы рәвештә дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган мәгълүматларның дөрес һәм тулы булуын танырга;

б) «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүенә контроль турында» Федераль законның 3 маддәсе 1 өлешенә ярашлы рәвештә дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган мәгълүматларның дөрес булмавын һәм тулы булмавын танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын күрергә һәм (яисә) чыгымнарга контроль нәтиҗәсендә алынган материалларны прокуратурага һәм (яисә), компетенцияләренә ярашлы рәвештә, башка дәүләт органнарына юлларга тәкъдим итә.

3.18. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пункты «д» пунктчасында күрсәтелгән сорауны карау буенча Комиссия Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче гражданинга карата түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) гражданинга коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмаларда вазыйфа биләүгә яисә коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмаларда граждан-хокукый шартнамә шартларында эшләр башкаруга рөхсәт бирергә, әгәр

әлеге оешма белән дәүләт идарә итүенең кайбер функцияләре аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына керсә;

б) гражданин тарафыннан хезмәт шартнамәсе шартларында коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмаларда вазыйфа биләү һәм (яисә) коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмаларда эшләр башкару (хезмәт күрсәтү) «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законның 12 маддәсе таләпләрен боза дип танырга. Бу очракта Комиссия министрга күрсәтелгән фактлар турында прокуратура органнарына һәм хәбәр салган оешмаларга мәгълүмат бирергә тәкъдим итә.

3.19. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пункты «а» - «д» пунктчаларында күрсәтелгән сорауларны карау нәтиҗәләре буенча, нигез булган очракта, Комиссия әлеге Нигезләмәнең 3.11 – 3.15.1, 3.17 – 3.18 пунктларында каралганнан үзгә карар кабул итә алалар. Мондый карар кабул итүнең нигезләре һәм мотивлары Комиссия утырышы беркетмәсендә чагылыш табарга тиеш.

3.20. Комиссия карарларын башкару өчен, Министрлыкның норматив хокукый актлары, министр карарлары һәм күрсәтмәләре проектлары әзерләнә ала, алар билгеләнгән тәртиптә министрга каралуга кертелә.

3.21. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктында күрсәтелгән сораулар буенча Комиссия карарлары яшерен тавыш бирү юлы белән (әгәр Комиссия башка төрле карар кабул итмәсә) утырышта катнашкан Комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә.

3.22. Комиссия карарлары, утырышта катнашкан Комиссия әгъзалары тарафыннан кул куелган беркетмәләрдә беркетелә. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пункты «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән сорауларны карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карар мәҗбүри характерда була.

3.23. Комиссия утырышы беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) Комиссия утырышының датасы, утырышта катнашкан Комиссия әгъзаларының һәм башка затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре;

б) хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтларын җайлау турында таләпләрнең үтәлеше турындагы сорау каралуга мөнәсәбәте булган дәүләт хезмәткәренең фамилиясен, исемен, атасының исемен, вазыйфасын күрсәтеп, Комиссия утырышында каралырга тиешле һәр сорауның формулировкасы;

в) дәүләт хезмәткәренә белдерелүче дәгъвалар, аларга нигез булып торган материаллар;

г) белдерелгән дәгъваларның асылы буенча дәүләт хезмәткәре һәм башка затлар тарафыннан язылган аңлатмаларның эчтәлеге;

д) утырышта чыгыш ясаган затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм чыгышларының кыскача эчтәлеге;

е) Комиссия утырышын үткәрү өчен нигез булып торган мәгълүматның чыганагы, мәгүълүматның Министрлыкка керү датасы;

ж) башка мәгълүматлар;

з) тавыш бирү нәтиҗәләре;

и) карар һәм аны кабул итүне нигезләү.

3.24. Комиссия карары белән риза булмаган Комисия әгъзасы үз фикерен

язмача язып тапшырырга хокуклы. Әлеге язмача фикер, Комиссия утырышы беркетмәсенә теркәлеп, дәүләт хезмәткәре аның белән таныш булырга тиеш.

3.25. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе утырыш үткәрелгән көннән соң 7 көн эчендә министрга, тулысынча яисә өземтә рәвешендә дәүләт хезмәткәренә, һәм шулай ук Комиссия карары буенча кызыксынган затларга юллана.

3.26. Министр Комиссия утырышы беркетмәсен карарга тиеш һәм, үз компетенциясе кысаларында, дәүләт хезмәткәренә карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул иткәндә, һәм шулай ук коррупциягә каршы торуны оештыруның башка сораулары буенча карар кабул иткәндә беркетмәдә күрсәтелгән тәкъдимнәрне исәпкә алырга хокуклы. Комиссия тәкъдимнәрен карау һәм кабул ителгән карар турында министр Комиссия утырышы беркетмәсе кертелгәннән соң бер ай вакыт эчендә язма формада Комиссиягә хәбәр сала. Министр карары Комиссиянең якындагы утырышында игълан ителә һәм тикшерүләрсез искә алына.

3.27. Комиссия тарафыннан дәүләт хезмәткәренең гамәлләрендә (гамәл кылмавында) дисциплинар гаеп билгеләре табылган очракта, бу турыда мәгълүмат дәүләт хезмәткәренә карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чарасын куллану турындагы сорауны хәл итү өчен министрга кертелә.

3.28. Комиссия дәүләт хезмәткәре тарафыннан административ хокук бозу яисә җинаять составы билгеләре булган гамәл кылу (гамәл кылмау) фактларын тапкан очракта, Комиссия рәисе күрсәтелгән гамәлнең (гамәл кылмауның) тормышка ашырылуы турында мәгълүматны һәм мондый фактны раслаучы документларны 3 көн эчендә, кирәк булганда, шунда ук хокук куллану органнарына тапшырырга тиеш.

3.29. Комиссия утырышы беркетмәсенң күчермәсе яисә беркетмәдән өземтә хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтларын җайлау турында таләпләрнең үтәлеше турындагы сорау каралуга мөнәсәбәте булган дәүләт хезмәткәренең шәхси эшенә беркетелә.

3.30. Комиссия карарыннан өземтә, Комиссия секретаре имзасы һәм Министрлык мөһере белән расланып, үзенә карата әлеге Нигезләмәнең 3.1 пункты «б» пунктчасының икенче абзацындагы сорау каралган Министрлыкта дәүләт граждан вазыйфасын биләүче гражданинга кул куйдырылып тапшырыла яисә аңа мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән адрес буенча, тапшырылу турында хәбәр беркетелгән заказлы хат итеп, Комиссиянең әлеге утырышы үткәннән соң килүче бер эш көненнән дә соңга калмый юллана.

3.31. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник һәм документацион яктан тәэмин итүне, һәм шулай ук Комиссия әгъзаларына көн тәртибенә кертелгән сораулар, утырышны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат бирүне, Комиссия әгъзаларын Комиссия утырышында тикшерелергә тәкъдим ителгән материаллар белән таныштыруны кадрлар бүлегенең коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты башкара.